ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31 август 2017ел. № 5057

Башкарма комитетның
аерым карарларына
үзгәрешләр кертү турында

РФ Торак кодексының 156 маддәсе 3 бүлеге, 158 маддәсенең 4 бүлеге, «Россия Федерациясе Торак кодексының 154 һәм 156 маддәләренә һәм «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 12 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 258-ФЗ санлы Федераль законның 1 маддәсе 2 пункты «в» пунктчасы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2017 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондындагы торак урыннан файдалану (наем өчен түләү), торакны карау һәм ремонтлау өчен түләү күләме турында» 2016 елның 29 декабрендәге 7163 нче карарына (Башкарма комитетның 2017 елның 28 июнендәге 3899 нчы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 нче кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль наем килешүләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу килешүләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү күләме һәм күп фатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында һәм (яки) торак урыннарын карау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннары милекчеләре өчен түләү күләме».

2. Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «2017 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондындагы торак урыннарыннан файдалану (наем өчен түләү), торак урыннарын карау һәм ремонтлау өчен түләү күләме турында» 2016 елның 29 декабрендәге 7163 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 28 июнендәге 3899 нчы карарының 2 пункты үз көчен югалткан дип танырга (рәсми басылган чыганак – http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының рәсми

хокукый мәгълүмат порталы, 2017 елның 29 июне, «Челнинские известия» газетасы, 2017 елның 30 июнендәге 47 нче сан).

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырырга һәм «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan ru Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет<br>
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин